

Дубенка районы Ломаты авылынын туган якны ойрәнv музеенын килvчеләр очен ишекләре һәрвакыт ачык.
Сигезенче январьда музейга Кемерово олкәсе Новокузнецк һәм Владимир олкәсе Камешково шәһәрләреннән авылдашлар һәм кунаклар килгән. Яна экспонатлар, документлар белән Новокузнецк шәһәреннән килгән Фаизә Айса кызы Ашированы, Камешково шәһәреннән Руфа Айса кызы Хусаинованы, Ломаттан Тәнзилә Айса кызы Пикеева белән Нәсимә Насрулла кызы Рахметуллованы музей житәкчесе Мәзидә Якуб кызы Муракаева таныштырган.

Бергә авыл тарихын, халкын искә алганнар, булган экспонатларны кулланып мичтә аш пешерvне, йон эрләvне искә тошергәннәр. Татарларга хас кунакчыллык традициясе буенча, милли камыр ризыклары белән чәй эчкәннәр.
Фаизә Айса кызы Аширова музейда алган жылы кичерешләре турында:
- Мин тагы Ломатта, биредә булуыма бик-бик шат. Авылыбызнын «Чишмә» ансамбленә Расих кардәшебез жибәргән гармунны бvләккә тапшырдым.



Ломаты авылынын туган якны ойрәнv музейда мин. Биредә аура әйбәт, тарих исләре анкып тора. Әти-әниләребез мирасын саклап янадан-яна экспонатлар, материаллар белән жиһазландырып торган Мәзидә белән Рафикка зур-зур рәхмәтләремне белдерәм. Якуб кызы Мәзидә vз урынында - әйбәт эшли, музейны баетып янадан-яна тарихи материаллар туплый, эчтәлекле экскурсияләр алып бара. Ломат халкым да музей белән горурлансыннар иде, чонки биредә әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез истәлекләре.
Жылы очрашу-экскурсия Ломатнын Семипалата урамындагы Анвяр Айса улы Аширов йорты янында дәвам иткән. Шул урында Анвяр Айса улын жылы искә алып, авылдашлары турында ул да кайгыртучанлык белдереп онытмыйча алар очен «Юлдаш» газетасын яна 2025 елнын ярты еллыгына яздырткан очен рәхмәтләрен белдерделәр.

Киләчәк буынга борынгы бабаларыбыз калдырган мирасны тукми-чәчми житкерергә тырыша Дубенка районы Ломаты авылы халкы. Вакыт ул бик тиз уза. Киләчәк буынга калдырасы мирасыбыз турында уйлыйк! Милли мәдәнияте, теле, сәнгате, гореф-гадәтләре, риваятьләре, дине яшәгәндә халык та яши.

**Наилә НАСЫРОВА**